

Авылларыбызнын сvнеп китvе кем очен дә яналык тvгел. Татар авыллары да кон аша генә тvгел, сәгать аша сvнеп китәләр. Чvп vләннәр баскан урамнарда бикләнгән, “сукырайган” ойләр кvбәя генә баралар. Бу авыллардан киткән халык чит якларда сагына торганнардыр туган жирләрен, ләкин кем дә кире кайтырга жиенмый. Кешләр генә тvгел, бvреләр дә сvнгән авыллар янына якын килмиләр.      Авылларыбыз донья йозендә азая бара. Ә бит телнен бишеге – авыл. Шәһәрләрдә бер генә тел кала бара – рус теле. Кем белә, кайчан булса инглиз яки китай теле генә калырга да момкин. Мордовиядә рус, мукшы, эрзя авыллары белән бергә татар авыллары да азая, юк була бара. Шулай ук – татар телебез дә халык иреннәрендә азая, сvнә, чит телгә әверелә. Сvнеп бара торган авылларда карт әбиләр генә бер бересе белән татарча сойләшергә кала. Ә аларнын оныклары каникулларга әти-әниләренен авылларына килгәндә кvбрәк русча сойләшергә тырышалар. Авылда ускән балалары да, шәһәргә киткәч, туган телләрендә азрак сойләшәләр. Кvбесе инде татарча сойләшә дә алмыйлар.
Ельник районында хәзер алты татар авылы калды. Ә берничә ел элек алар жидәv иделәр. Бересе мәнгегә сvнеп китте. Бу – Иске Кадеш авылы. Матур урын да бит анда: авылнын бер ягында – Мокша елгасы ага, ә икенче ягында – ураманнар шаулый. Кайчандыр Иске Кадешка мукшы гаиләләре кvрше Мордовские Пошаты авылыннан торырга урнашкан булганнар, татар ойләре янында vз ойләрен салганнар. Мукшылар бик яхшы татар телен ойрәнгәннәр, аларнын татарча сойләшvләрен ишеткәч, мукшыларны татардан аерып та булмаган. Мин vзем дә бала чагымда татарча сойләшә торган мукшыларны, русларны кvп кенә ишетә идем, алар мина татарлар диеп кvренәләр иде. Чын да: милләтне саклаганда беренчедән телне сакларга кирәк. Ә татар телен белә торган рус та, мукшы да татар кешесе кебек кvренә.
Иске Кадешта янгыраулы фамилияле кешеләр яшәделәр: Тенишевлар, Бахтияровлар. Кvрәсен, татар тарихында тирән, якты эз калдырган кешеләр кавымыннан чыкканнардыр Иске Кадешнын сонгы тормышчылары. Нурлы кояш астында vзен хәзер дә саклап кала торган Яна Кадеш авылында да янгырый торган фамилияле кешеләр бvген яшиләр: Суховлар, Богдановлар, Бахтияровлар. Яна Кадешны Иске Кадеш белән Мокша елгасы аера иде.
Иске Кадешны юлсызлык, эшсезлек сvндерде: халык китеп барды – кайсы кая. Кемнәрдер туганары янына Питергә, Горькийга киттеләр, ә кайсылары безнен Кvгеш (Акчеево) авылына уршатылар. Иске Кадеш белән Кvгешнен арасы – ике-оч чакрым.

Бер мукшы фермеры тетелгән Иске Кадешны терелтергә алынган иде – андагы жирләрне арендага алып, ләкин анын эше чыкмады. Шул фермердан сон Иске Кадеш жирләрендә бурьян белән кечеркән кvбәйде генә...
Шулай сvнәләр авылларыбыз – татар теленен бишекләре. Ельник районынын калган алты авылынын да киләчәге бик кvнелле тvгел. Халык азая, ойләр сvнә, урамнар буш калалар. Шәһәргә киткән малайлар, кызлар туган авылларына кайтырга ашыкмыйлар. Авылда – эшсезлек, акчазызлык, кvнелсезлек. Авыл тормышы тиздән vзгәрмәс тә, кvрәсен. Россия авылларын саклый алмады. Сакларга да теләмәдеме? Сугышлардан, революцияләрдән сон авылларын сакларга хәле дә калмадымы?
Нәрсә эшләп була? Ничек татар телен, татарлыкны безгә сакларга? Кvнелдә калдырырга татарлыкны, шәһәргә килгәч тә татарлыкны кvнелдән ташламаска, татар телен шәһәрдә дә онытмаска. Гаиләдә кvбрәк татарча сойләшергә, татар китаплары, газеталары, журналлары укырга, татар жырлары тыннарга. Башка юл юк. Шулай булмаса – милләт сакланмас. «Телсез татар татар була ала, телсез татар милләт булалмый” . Шулай Татарстаннын халык шагыйре Роберт Миннуллин бер шигерендә әйткән иде...
Татар – зур тарихлы халык. Сvнә торган авыллары артыннан татар сvнәргә тиеш тvгел. Ышанырга телим: татар шәһәрдә дә vзенен саклануы юлын табар, татар теле буыннарда да, кvнелләрдә дә янгырый торган тел булып калыр...
Бvгенге кондә безнен азая торган авылларыбызда да мәчетләр ачылган, муллаларабыз бар. Мәчеткә йорvчеләр бик аз калса да, мәчетләр булуы кечкенә татар авылларынын да татарлыгын сакларга ярдәм итә, халыкка милләт булып калырга булыша.
Ә сvнгән яки сvнә торган татар авылларын еш кына сагынам. Бигрәк тә – Ельник районынын татар авылларын. Жилләр исә, жилләр исvдән агачлар шаулый. Агачлар – сойләшә. Мина шулай ишетелә: татар авылларында vсә торган агачлар да – татарча сойләшә.
Агачлар гына татарча сойләшvче булып калмас дип уйлым. Аллага шокер, безнен Мордовиядә бvген дә сvнеп китә торган авыллардан башка унышлы яши торган татар авыллары да бар әле...

**Румия Рамаева**